## 1.Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

**Сыйныф**: 5“Б”.
**Уку планы буенча**
**Туган әдәбияттан**: **35**сәг.
**Атнага**: 1 сәг.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р,Л. Малафеева., 2014 ел
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында төп гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019уку елына укыту планы (№ 1 педсовет протоколы, 31 август 2018 ел).

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә фәнне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда әдәби укуның роле һәм мөһимлеге турында
күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятkә карата ихтирам хисе уята,
ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

**Гомуми нәтиҗәләр:**

– укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, телдән аралашу күнекмәләре булдыру;
– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
- фәнгә карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм уңышлы үзләштерергә шартлар тудыру.

**Шәхси нәтиҗәләр:**

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда фәнгә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

***Танып белү***:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
- рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
- укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

***Регулятив:***

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив*:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

## II.Туган тел укытуның төп эчтәлеге

## III. Укыту предметын календарь – тематик планлаштыру

| № | Дәреснең темасы | Сәгать саны | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **дата** | **факт** |
| 1 | Куркынычсызлык кагыйдәләре. Татар халык авыз иҗаты. Әкиятләр. | 1 | Фольклор жанры турында белешмә алу, әкият төшенчәсен аңлау, аның төрләре, төзелеше белән танышу. | 6.09 | |
| 2 | "Зирәк карт" әкияте. | 1 | Әкиятне сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйләү. Әкият геройларына хас шәфкатьлелек, миһербанлылык сыйфатлары. | 13.09 | |
| 3 | "Җил арба" әкияте. | 1 | Әкиятнең эчтәлеген сөйләү. Татар халык әкиятләренә хас үзенчәлек. Уңай һәм тискәре сыйфатларны билгели алу, чагыштырып нәтиҗә ясый белү. | 20.09 | |
| 4 | **Дәрес-проект.Әкияттә кунакта.** | 1 | Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Әкият һәм фантастика темаларын гомумиләштереп кабатлау, әкият белән фантастиканы аера белү күнекмәләре булдыру. | 27.09 | |
| 5 | Мәкальләр һәм әйтемнәр. | 1 | Мәкаль һәм әйтемнәр турында төшенчә. | 4.10 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Аларның табигатенә хас төп сыйфатлар. Мәкаль-әйтемнәрдә мәгънә тирәнлеге һәм аларның тел-бизәк, сөйләмнең тәэсирлеген көчәйтү чаралары булуы. | | |
| 6 | Табышмаклар, әкият-табышмаклар, тизәйткечләр һәм шарадалар.Халык авыз иҗаты һәм язма әдәбият. | 1 | Табышмакларның килеп чыгышы. Табышмаклар әйтешү ярышы. Тизәйткечләр әйтү.Халык авыз иҗаты һәм язма әдәбият арасындагы бәйләнеш. | 11.10 | |
| 7 | Каюм Насыйриның ”Патша һәм карт”,”Угрының таягы озын”,”Бай һәм хезмәтче”, ”Ата һәм ул”хикәятләре. Әдәбият – сүз сәнгате. | 1 | Хикәятләрдәге уртак сыйфатларны,алардан чыга торган төп нәтиҗәне билгеләү.Матур әдәбият турында төшенчә. | 18.10 | |
| 8 | Г.Тукайның "Эшкә өндәү", "Сабыйга" "Эш беткәч, уйнарга ярый" шигырьләре. | 1 | Шагыйрьнең мәгърифәткә, яшьләргә белем һәм тәрбия бирүгә мөнәсәбәте. Шигырьләрне сәнгатьле уку, ятлау. | 25.10 | |
| 9 | Г.Тукайның "Су анасы" әкият-поэмасы. Шигырь. Ритм. Рифма.<br>Строфа. | 1 | Шагыйрьнең бала психологиясен сурәтләве. Шигырь эчтәлеге буенча фикер алышу. | 18.11 | |
| 10 | **БСҮ Тукай – халык хәтерендә.** | 1 | Г.Тукай исеме белән бәйле истәлекле урыннар. Бирелгән темага, куелган максатка яраклы рәвештә телдән белемнәрен һәм фикерләрен җиткерә белү күнекмәсенә ия булу | .15.11 | |
| 11 | М. Гафуриның "Кыр казы" хикәясе.Хикәя турында төшенчә. | 1 | План нигезендә эчтәлек сөйләү. Табигатькә сакчыл караш. | 22.11 | |
| 12 | **Сочинение. Кошлар - безнең дусларыбыз.** | 1 | Бәйләнешле фикерли белү сәләтен, дөрес җөмләләр төзү осталыгын үстерү. | 29.11 | |
| 13 | Галимҗан Ибраһимов турында белешмә. “Яз башы" хикәясе. | 1 | Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты, “Яз башы” әсәре белән танышу. | 6.12 | |
| 14 | **Сочинение. Туган ягым табигате.** | 1 | Бәйләнешле фикерли белү сәләтен,дөрес җөмләләр төзү осталыгын үстерү. | 13.12 | |
| 15 | Ф.Кәримнең “Кыр казы”шигыре. | 1 | Сәнгатьле уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр аша лирик әсәрне анализлау. | 20.12 | |
| 16 | Ф. Кәримнең "Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл" әкияте. | 1 | Әсәрнең идеясе һәм үзенчәлеге. Әкияттә хайваннар образының бирелеше. | 10.01 | |
| 17 | **Дәрес-проект. Әсәр буенча инсценировка әзерләү.** | 1 | Әкият буенча инсценировка әзерләү. | 17.01 | |
| 18 | А.Алишның "Сертотмас | 1 | Хайваннар турында әкиятләрнең | 24.01 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Үрдәк" әкияте.А.Алиш – талантлы әкиятче. | | үзенчәлеге. Хайваннарга бәя бирү. | | |
| 19 | **БСҮ. “Минем яраткан йорт хайваным” темасына әңгәмә** | 1 | Йорт хайваннары турында табышмаклар һәм мәкальләр уку, фикер алышу, шигырьләр уку. | 31.01 | |
| 20 | А. Алишның "Чуар тавык" хикәясе. | 1 | Эчтәлек сөйләү күнекмәләрен үстерү. Фикереңне эзлекле итеп белдерә белү. | 7.02 | |
| 21 | Г. Исхакыйның" Кәҗүл читек" хикәясе. | 1 | Г.Исхакыйның психологик сурәтләү алымнары. Әсәрне аңлату, сөйләү, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару. | 14.02 | |
| 22 | Дәрҗия Аппакова иҗаты. "Йолдызкай" хикәясе. | 1 | Тормыш юлы турыщда белешмә. Йорт хайваннары, аларның кирәклеге турында мәгълүмат. | 21.02 | |
| 23 | Д. Аппакова "Шыгырдавыклы башмаклар" хикәясе. | 1 | Бергәләп анализ ясау, образларга характеристика бирү. | 28.02 | |
| 24 | Ф.Хөснинең “Чыбыркы” хикәясе.Әдәбият теориясе (эчтәлек һәм форма) | 1 | Әсәрне уку, эчтәлекне үзләштерү, сюжет элементларын өйрәнү. | 7.03 | |
| 25 | Нәби Дәүли иҗаты. "Бәхет кайда була?" шигыре. | 1 | Язучы иҗатына күзәтү ясау, шигырен укып, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, аңа бәя бирү.“Бәхет кайда була?” шигырен өйрәнү, бәхет турында сөйләшү. | 14.03 | |
| 26 | **БСҮ Нәрсә ул бәхет?** | 1 | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | 21.03 | |
| | | | | | |
| 27 | Ш.Галиевнең “Телләр белүче каләм”, “Магнитофон онытмый” Шигырьләре | 1 | Шигырьләрне укып, сораулар буенча анализлау, нәтиҗәләр ясау. | 4.04 | |
| 28 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” пьесасы ( 1 нче күренеш) | 1 | Рольгә кереп,образларны тулысы белән ачып укый белү. | 11.04 | |
| 29 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” пьесасы ( 2 нче күренеш) | 1 | Әсәрнең төп идеясен билгеләү,рольләргә бүлеп уку. | 18.04 | |
| 30 | **БСҮ “Үзем турында үзем” темасына сөйләшү.** | 1 | Сорауларга нигезләнеп, үзең турында сөйли белү. | 25.04 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 31 | Н.Исәнбәтнең “Син сазыңны уйнадың” шигыре. | 1 | Шигырен укып, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, аңа бәя бирү | 2.05 | |
| 32 | **Дәрес-проект. Гүзәл табигатьле туган җирем.** | 1 | Картина аша әйтергә теләгән фикерләрне сүз белән әйтергә өйрәтү. | 9.05 | |
| 33 | Ф.Яруллинның “Кояштагы тап”әкияте. | 1 | Эчтәлекне аңлау, төшенү күнекмәләре булдыру | 16.05 | |
| 34 | **ДТУ Ф. Яруллин. “Йолдыз тапкан кыз”.** | 1 | Бергәләп анализ ясау, образларга характеристика бирү. | 23.05 | |
| 35 | Йомгаклау дәресе. | 1 | Еллык эшкә нәтиҗәләр ясау, фикереңне эзлекле итеп белдерә белү. | 30.05 | |